СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 111

**2024 елның 27 мартында кабул ителгән 98 номерлы «Җир салымы турында» гы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. 2024 елның 27 мартында кабул ителгән 98 номерлы «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның «б» пунктчасында «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен «, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның «в» пунктчасына «, әлеге пунктчада күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3. 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тәэсир итә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге башлыгы өстенә йөкләргә.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х. Заляев